**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О регулировании отдельных вопросов налогообложения при реализации региональных инвестиционных проектов на территории Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
16 марта 2022 года

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

1. Настоящий Закон в соответствии со статьей $284^{3}$ Налогового кодекса Российской Федерации устанавливает налоговую ставку по налогу на прибыль организаций, подлежащему зачислению в бюджет Республики Татарстан, для участников региональных инвестиционных проектов, реализуемых на территории Республики Татарстан (далее – региональные инвестиционные проекты).

2. Настоящий Закон в соответствии с главой $3^{3}$ Налогового кодекса Российской Федерации устанавливает дополнительное требование к региональным инвестиционным проектам, порядок принятия решения о включении организации в реестр участников региональных инвестиционных проектов (далее – реестр) или об отказе во включении организации в реестр, порядок и условия принятия решения о внесении изменений в реестр, не связанных с прекращением статуса участника регионального инвестиционного проекта.

Статья 2. **Налоговая ставка по налогу на прибыль организаций**

Для участников региональных инвестиционных проектов устанавливается налоговая ставка по налогу на прибыль организаций, подлежащему зачислению в бюджет Республики Татарстан, в размере 10 процентов начиная с налогового периода, в котором в соответствии с данными налогового учета была получена первая прибыль от реализации товаров, произведенных в результате реализации регионального инвестиционного проекта, и заканчивая отчетным (налоговым) периодом, в котором разница между суммой налога на прибыль организаций,

рассчитанной исходя из налоговой ставки по налогу на прибыль организаций в размере 20 процентов, и суммой налога на прибыль организаций, исчисленного с применением налоговых ставок по налогу на прибыль организаций, установленных настоящей статьей и пунктом $1^5$ статьи 284 Налогового кодекса Российской Федерации, определенная нарастающим итогом за указанные отчетные (налоговые) периоды, составила величину, равную объему осуществленных в целях реализации инвестиционного проекта капитальных вложений, определяемому в соответствии с пунктом 8 статьи $284^3$ Налогового кодекса Российской Федерации.

Статья 3. **Дополнительное требование к региональным инвестиционным проектам**

В дополнение к требованиям, установленным статьей $25^8$ Налогового кодекса Российской Федерации, региональный инвестиционный проект должен быть включен в перечень инвестиционных проектов по строительству (реконструкции, модернизации) генерирующих объектов, функционирующих на основе использования отходов производства и потребления, отобранных по результатам конкурса, проведенного в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации от 27 декабря 2010 года № 1172 «Об утверждении Правил оптового рынка электрической энергии и мощности и о внесении изменений в некоторые акты Правительства Российской Федерации по вопросам организации функционирования оптового рынка электрической энергии и мощности».

Статья 4. **Порядок принятия решения о включении организации в реестр или об отказе во включении организации в реестр, порядок и условия принятия решения о внесении изменений в реестр, не связанных с прекращением статуса участника регионального инвестиционного проекта**

1. Принятие решений о включении организации в реестр или об отказе во включении организации в реестр, о внесении изменений в реестр, не связанных с прекращением статуса участника регионального инвестиционного проекта, а также иные полномочия, предусмотренные статьями $25^{10}$ – $25^{12}$ Налогового кодекса Российской Федерации, осуществляются органом исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющим государственное управление в сфере экономического развития (далее – уполномоченный орган).

2. Для включения в реестр организация направляет в уполномоченный орган составленное в произвольной форме заявление о включении в реестр (далее – заявление) с приложением документов, указанных в пункте 1 статьи $25^{11}$ Налогового кодекса Российской Федерации.

3. Уполномоченный орган в течение трех рабочих дней со дня представления заявления и документов, указанных в пункте 1 статьи $25^{11}$ Налогового кодекса Российской Федерации, направляет организации решение о принятии заявления к

рассмотрению или об отказе в принятии заявления к рассмотрению в случае непредставления документов, указанных в подпунктах 1, 4 и 5 пункта 1 статьи $25^{11}$ Налогового кодекса Российской Федерации.

4. Решение о включении организации в реестр или об отказе во включении организации в реестр принимается уполномоченным органом в течение 30 дней со дня направления организации решения о принятии заявления к рассмотрению.

5. Основанием для принятия решения об отказе во включении организации в реестр является несоблюдение требований, установленных Налоговым кодексом Российской Федерации и настоящим Законом к региональным инвестиционным проектам.

6. Уполномоченный орган в течение пяти дней со дня принятия решения о включении организации в реестр или об отказе во включении организации в реестр направляет соответствующее решение организации.

7. Решение о внесении изменений в реестр, не связанных с прекращением статуса участника регионального инвестиционного проекта, принимается уполномоченным органом в случае внесения в инвестиционную декларацию изменений, касающихся условий реализации регионального инвестиционного проекта, при условии соблюдения требований, предъявляемых к региональным инвестиционным проектам и (или) их участникам, установленных Налоговым кодексом Российской Федерации и настоящим Законом, в течение 10 дней со дня принятия уполномоченным органом решения о внесении изменений в инвестиционную декларацию.

8. Внесение в инвестиционную декларацию изменений, касающихся условий реализации регионального инвестиционного проекта, осуществляется уполномоченным органом на основании заявления участника регионального инвестиционного проекта, составленного в произвольной форме, содержащего обоснование необходимости внесения таких изменений, в порядке, предусмотренном настоящей статьей для включения организации в реестр.

9. Уполномоченный орган отказывает участнику регионального инвестиционного проекта во внесении изменений в инвестиционную декларацию по основаниям, предусмотренным пунктом 3 статьи $25^{12}$ Налогового кодекса Российской Федерации.

10. Уполномоченный орган в течение пяти дней со дня принятия решения о внесении изменений в реестр, не связанных с прекращением статуса участника регионального инвестиционного проекта, или об отказе во внесении изменений в реестр направляет соответствующее решение участнику регионального инвестиционного проекта.

11. Решения о включении организации в реестр, о внесении изменений в реестр, не связанных с прекращением статуса участника регионального инвестиционного проекта, а также иные необходимые сведения направляются уполномоченным органом в электронной форме в федеральный орган исполнительной власти, уполномоченный по контролю и надзору в области налогов и сборов, в течение трех рабочих дней со дня принятия соответствующего решения.

Статья 5. **Вступление в силу настоящего Закона**

1. Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2023 года и действует до 1 января 2029 года, за исключением случая, предусмотренного частью 2 настоящей статьи.

2. Участники региональных инвестиционных проектов, удовлетворяющих требованиям, установленным абзацем вторым подпункта 4 пункта 1 статьи $25^{8}$ Налогового кодекса Российской Федерации, утрачивают право на применение налоговой ставки по налогу на прибыль организаций, установленной статьей 2 настоящего Закона, начиная с 1 января 2027 года.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
21 марта 2022 года
№ 11-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы территориясендә региональ инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда салым салуның аерым мәсьәләләрен җайга салу турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 16 мартында
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Россия Федерациясе Салым кодексының $284^{3}$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырыла торган региональ инвестиция проектларында (алга таба – региональ инвестиция проектлары) катнашучылар өчен оешмалар табышына Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле салым буенча салым ставкасын билгели.
2. Әлеге Закон Россия Федерациясе Салым кодексының $3^{3}$ бүлеге нигезендә региональ инвестиция проектларына өстәмә таләпне, оешманы региональ инвестиция проектларында катнашучылар реестрына (алга таба – реестр) кертү яисә оешманы реестрга кертүдән баш тарту турында карар кабул итү тәртибен, реестрга региональ инвестиция проектында катнашучы статусын туктатуга бәйле булмаган үзгәрешләр кертү хакында карар кабул итү тәртибен һәм шартларын билгели.

2 статья. **Оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы**

Региональ инвестиция проектларында катнашучылар өчен оешмалар табышына Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле салым буенча салым ставкасы, салым исәбе мәгълүматлары нигезендә региональ инвестиция проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә җитештерелгән товарларны сатудан беренче табыш алынган салым чорыннан башлап һәм оешмалар табышына салым буенча 20 процент күләмендәге салым ставкасыннан чыгып исәпләнгән оешмалар табышына салым суммасы һәм оешмалар табышына салым буенча әлеге статьяда һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 284 статьясындагы $1^{5}$ пунктында билгеләнгән салым ставкаларын кулланып исәпләнгән оешмалар табышына салым

суммасы арасындагы аерма булган хисап (салым) чоры белән тәмамлап, 10 процент күләмендә билгеләнә, бу аерма әлеге хисап (салым) чорларында үсеп килүче нәтиҗә белән билгеләнә һәм инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында башкарылган капитал салуларның Россия Федерациясе Салым кодексының $284^3$ статьясындагы 8 пункты нигезендә билгеләнә торган күләменә тигез булган күләмне тәшкил итә.

3 статья. **Региональ инвестиция проектларына өстәмә таләп**

Россия Федерациясе Салым кодексының $25^8$ статьясында билгеләнгән таләпләргә өстәмә рәвештә региональ инвестиция проекты «Электр энергиясен һәм егәрлеген күпләп сату базары кагыйдәләрен раслау турында һәм электр энергиясен һәм егәрлеген күпләп сату базарының эшләвен оештыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 27 декабрендәге 1172 номерлы карары нигезендә үткәрелгән конкурс нәтиҗәләре буенча сайлап алынган җитештерү һәм куллану калдыкларыннан файдалану нигезендә эшли торган генерация объектларын төзү (реконструкцияләү, модернизацияләү) буенча инвестиция проектлары исемлегенә кертелергә тиеш.

4 статья. **Оешманы реестрга кертү яисә оешманы реестрга кертүдән баш тарту турында карар кабул итү тәртибе, реестрга региональ инвестиция проектында катнашучы статусын туктатуга бәйле булмаган үзгәрешләр кертү хакында карар кабул итү тәртибе һәм шартлары**

1. Оешманы реестрга кертү яисә оешманы реестрга кертүдән баш тарту, реестрга региональ инвестиция проектында катнашучы статусын туктатуга бәйле булмаган үзгәрешләр кертү турында карарлар кабул итү, шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының $25^{10} – 25^{12}$ статьяларында каралган башка вәкаләтләр Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең икътисадый үсеш өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Реестрга кертү өчен оешма вәкаләтле органга, Россия Федерациясе Салым кодексының $25^{11}$ статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән документларны кушып, реестрга кертү турында ирекле рәвештә төзелгән гариза (алга таба – гариза) җибәрә.

3. Вәкаләтле орган гариза һәм Россия Федерациясе Салым кодексының $25^{11}$ статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылган көннән алып өч эш көне эчендә оешмага гаризаны карауга алу яисә, Россия Федерациясе Салым кодексының $25^{11}$ статьясындагы 1 пунктының 1, 4 һәм 5 пунктчаларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, гаризаны карауга алудан баш тарту турында карар җибәрә.

4. Оешманы реестрга кертү яисә оешманы реестрга кертүдән баш тарту турындагы карар вәкаләтле орган тарафыннан оешмага гаризаны карауга алу хакында карар җибәргән көннән алып 30 көн эчендә кабул ителә.

5. Россия Федерациясе Салым кодексында һәм әлеге Законда региональ инвестиция проектларына карата билгеләнгән таләпләрне үтәмәү оешманы реестрга кертүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез була.

6. Вәкаләтле орган оешманы реестрга кертү яисә оешманы реестрга кертүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә оешмага тиешле карар җибәрә.

7. Реестрга региональ инвестиция проектында катнашучы статусын туктатуга бәйле булмаган үзгәрешләр кертү турындагы карар, Россия Федерациясе Салым кодексында һәм әлеге Законда билгеләнгән, региональ инвестиция проектларына һәм (яисә) аларда катнашучыларга карата куела торган таләпләрне үтәү шарты белән, инвестиция декларациясенә региональ инвестиция проектын гамәлгә ашыру шартларына кагылышлы үзгәрешләр кертелгән очракта, вәкаләтле орган тарафыннан ул инвестиция декларациясенә үзгәрешләр кертү хакында карар кабул иткән көннән алып 10 көн эчендә кабул ителә.

8. Инвестиция декларациясенә региональ инвестиция проектын гамәлгә ашыру шартларына кагылышлы үзгәрешләрне кертү вәкаләтле орган тарафыннан региональ инвестиция проектында катнашучының ирекле рәвештә төзелгән, мондый үзгәрешләрне кертү зарурлыгын нигезләве булган гаризасы нигезендә оешманы реестрга кертү өчен әлеге статьяда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

9. Вәкаләтле орган инвестиция декларациясенә региональ инвестиция проектында катнашучының үзгәрешләрен кертүдән Россия Федерациясе Салым кодексының $25^{12}$ статьясындагы 3 пунктында каралган нигезләр буенча баш тарта.

10. Вәкаләтле орган реестрга региональ инвестиция проектында катнашучы статусын туктатуга бәйле булмаган үзгәрешләр кертү яисә реестрга үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә региональ инвестиция проектында катнашучыга тиешле карар җибәрә.

11. Оешманы реестрга кертү, реестрга региональ инвестиция проектында катнашучы статусын туктатуга бәйле булмаган үзгәрешләр кертү турындагы карарлар, шулай ук башка кирәкле белешмәләр вәкаләтле орган тарафыннан электрон рәвештә федераль башкарма хакимиятнең салымнар һәм җыемнар өлкәсендәге контроль һәм күзәтчелек буенча вәкаләтле органына тиешле карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә җибәрелә.

5 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм, әлеге статьяның 2 өлешендә каралган очрактан тыш, 2029 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә була.

2. Россия Федерациясе Салым кодексының $25^{8}$ статьясындагы 1 пунктының 4 пунктчасындагы икенче абзацында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган региональ инвестиция проектларында катнашучылар әлеге Законның 2 статьясында билгеләнгән оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын куллану хокукын 2027 елның 1 гыйнварыннан башлап югалталар.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 21 март
№ 11-ТРЗ